**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2014 елның 24 апреле 165№

Әлки муниципаль районы автоном яисә
бюджет учреждениесенең аеруча кыйммәтле
күчемле мөлкәтенең төрләрен һәм исемлеген
билгеләү тәртибе турында

2010 елның 8 маендагы «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 83-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 июлендәге «Автономияле яисә бюджет учреждениесе мөлкәтен аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт категориясенә кертү тәртибе турында» 538 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Билгеләргә:

Әлки муниципаль районы автоном яисә бюджет учреждениеләрен гамәлгә куючы функция һәм вәкаләтен гамәлгә ашыручы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Әлки муниципаль районының автоном яисә бюджет учреждениеләренең аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәте төрләрен һәм исемлеген билгели;

Әлки муниципаль районының автоном яисә бюджет учреждениеләренең аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәте исемлеген билгеләгәндә мондый мөлкәт составына кертелергә тиеш:

баланс бәясе 50 мең сумнан 200 мең сумга кадәр булган күчемле милек;

Әлки муниципаль районының автоном яисә бюджет учреждениесе тарафыннан аның уставында каралган эшчәнлекнең төп төрләрен гамәлгә ашыру шактый кыенлаштырылачак һәм (яки) әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә аеруча кыйммәтле күчемсез милекнең билгеле бер төренә кертеләчәк башка күчемсез милек;

читләштерелүе Россия Федерациясе законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән махсус тәртиптә гамәлгә ашырыла торган мөлкәт, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фонды һәм милли китапханә фонды документлары.

3. Әлки муниципаль районының автоном һәм бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә, Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир

мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә, аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт исемлеген раслауга әзерләргә.

4. Аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт исемлеген алып бару Әлки муниципаль районы учреждениеләренең бухгалтерлык исәбе белешмәләре нигезендә Әлки муниципаль районының бюджет яисә автоном учреждениесе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәткә, аның баланс бәясенә һәм инвентар (исәпкә алу) номерына (ул булганда) кертелгән объектның тулы исеме турында белешмәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының автоном һәм бюджет учреждениеләренең аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәте турында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль милек мөлкәте реестрына тиешле белешмәләр кертергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе В.М. Петровка йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: А. Ф. Никошин